**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

____________ _______

**2030 елга кадәр Актаныш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 5 апрелендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Актаныш муниципаль районы Советының «Актаныш муниципаль районының 2021 елга кадәр һәм 2030 елга кадәр план чорына социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслау турында» 2016 елның 28 сентябрендәге 10-05 санлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районының 2030 елга кадәр социаль-икътисади үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планын расларга һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад буенча җитәкчесе урынбасары Л.Р.Сираевага йөкләргә.

Җитәкче урынбасары Р.А.Ильясов